РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

«29» декабрь 2018 № 880

Теләче муниципаль районы җирле үзидарәләре һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, ирекләләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара ярдәмләшү тәртибен раслау турында

1995 елның 11 августындагы 135 санлы «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекләлек (волонтерлык) турында»гы Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга, РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 28 ноябрендәге 1425 санлы «Башкарма хакимиятнең федераль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, алар ведомствосындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең, башка оешмаларның ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, ирекләләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара ярдәмләшү тәртибенә гомуми таләпләрне һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, алар ведомствосындагы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең, башка оешмаларның ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән үзара ярдәмләшү тәртибе раслана торган эшчәнлек төрләрен раслау турында»гы Карарына, Татарстан Республикасының 2018 елның 21 июнендәге 48 санлы «Ирекләлек (волонтерлык) өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне көйләү турында һәм Татарстан Республикасының кайбер законнар актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Карарына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы җирле үзидарәләре һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, ирекләләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара ярдәмләшү тәртибен кушымта буенча расларга.

2. Әлеге карарны рәсми төстә бастырып чыгарырга.

3. Карар үтәлешенә контрольне Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елгы 880 санлы
карарына кушымта

Теләче муниципаль районы җирле үзидарәләре һәм муниципаль учреждениеләренең ирекледәр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, ирекледәр (волонтерлык) оешмалары белән үзара ярдәмләшү тәртибе

1. Ирекледәр (волонтерлык) эшчәнлеге расланган Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларда түләүсез эшләр башкару һәм (яки) хезмәт күрсәтү формасындагы ирекле эшчәнлекне күздә тота.

2. Җирле үзидарә органнары ирекледәрне (волонтерларны) ирекледәр (волонтерлык) эшчәнлегенә тартырга хокуклы.

3. Ирекледәр (волонтерлык) эшчәнлеге түбәндәге максатларда башкарыла:

Гражданнарны социаль яклау һәм саклау, аз керемлеләрнең матди хәлен яхшыртуны да кертеп, эшсезләрне, инвалидларны һәм үзләренең физик һәм интеллектуаль үзенчәлекләре, башка шартлар аркасында үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыра алмаучыларны социаль реабилитацияләү:

- халыкны тәбигый бәла-казаларның, экология, сәнәгать яки башка һәлакәтләр нәтиҗәләрен җиңеп чыгуга әзерләү;

- тәбигый бәла-казалар, экология, сәнәгать яки башка һәлакәтләр, социаль, милли, дини конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә, репрессия корбаннарына, качакларга һәм мәҗбүри күченеп килүчеләргә ярдәм күрсәтү;

- халыклар арасында тынычлыкны, дуслыкны һәм бердәмлекне ныгытуга, социаль, милли, дини конфликтларны булдырмауга булышлык итү;

- җәмгыятьтә гаиләнең абруен һәм ролен ныгытуга булышлык итү;

- ана булуны, балалыкны һәм ата булуны яклауга булышлык итү;

- белем бирү, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеккә, шәхеснең рухи үсешенә булышлык итү;

- гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм профилактика өлкәсендәге эшчәнлеккә, шулай ук сәламәт тормыш рәвеше алып бару, гражданнарның мораль-психологик хәлен яхшыртуга булышлык итү;

- физик культура һәм спорт (профессиональ спорттан тыш) өлкәсендәге эшчәнлеккә булышлык итү, физкультура һәм спорт чараларын оештыруда һәм үткәрүдә физик затлар тарафыннан түләүсез эшләр башкару һәм (яки) хезмәт күрсәтү;

- тирә-як мохитне һәм хайваннарны саклау;

- биналарны, объектларны һәм тарихи, гыйбадәт кылу, мәдәни яки табигате саклана торган биләмәләрне һәм җирләү урыннарын саклау һәм тиешенчә карап тору;

- халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклануга әзерләү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча белемнәрне пропагандалау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

- ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән башка калган балаларны, караучысыз калган балаларны, авыр тормыш хәлендәге балаларны социаль реабилитацияләү;

- халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм хокукый белемнәрен арттыру;

- ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлегенә булышлык итү;

- балигъ булмаганнарның караучысыз калуына һәм хокук бозуларына профилактика үткәрү буенча эшчәнлектә катнашу;

- балаларның һәм яшьләрнең фәнни-техник, сәнгать иҗатын үстерүгә булышлык итү;

- балаларны һәм яшьләрне патриотик, рухи-әхлакый тәрбияләүгә булышлык итү;

- иҗтимагый әһәмияткә ия булган яшьләр инициативаларына, проектларына, балалар һәм яшьләр хәрәкәтләренә, балалар һәм яшьләр оешмаларына булышлык күрсәтү;

- социаль рекламалар җитештерү һәм (яки) тарату буенча эшчәнлеккә булышлык итү;

- гражданнарның үз-үзен тотышларында социаль яктан куркыныч булган формаларга профилактика үткәрүгә булышлык итү.

4. Ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручылар, ирекләләр (волонтерлык) оешмалары, үзара ярдәмләшүне тәэмин итү максатыннан, җирле үзидарә органнарына, учреждениеләргә һәм (яки) оешмаларга почта аша исемлекне салып яки Интернет челтәре аша электрон документ формасында, ирекләләр эшчәнлеген оештыруда үзара ярдәмләшү турында түбәндәге мәгълүматлар булган тәкъдим (алга таба - тәкъдим) җибәрә:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), әгәр ирекләләр эшчәнлеген оештыручы физик зат булса;

б) оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм контактлары яки ирекләләр эшчәнлеген оештыручы юридик зат булганда, аның вәкиленең телефон номеры, электрон почтасы, адресы;

в) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрындагы дәүләт теркәү номеры;

с) Интернет челтәрендәге рәсми сайтының яки рәсми битенең адресы турында мәгълүматлар (булган очракта);

д) иреклелек (волонтерлык) үсеше өлкәсендәге Бердәм мәгълүмат системасында булган идентификацион номер;

е) "Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында"гы Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 2 статьясының 1 пунктында каралган максатларда, ирекләләр тарафыннан башкарылырга тәкъдим ителә торган эшләр (хезмәтләр) исемлеге, хезмәт күрсәтү шартлары, шул исәптән эшнең (хезмәт күрсәтүнең) срогы һәм күләме, ирекләләрнең (волонтерларның) хәзерлек дәрәҗәсе, компетенциясе, белем дәрәҗәсе һәм

һөнәри осталыгы, ирекләләр эшчәнлеген оештыручының, ирекләләр оешмасының тиешле тәҗрибәсе һәм Россия Федерациясе законнары белән гамәлгә кергән башка таләпләр.

5. Җирле үзидарә органы, учреждение һәм (яки) оешма, тәкъдим кергәннән соң 10 эш көне эчендә аны карап, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- тәкъдимне кабул итү турында;
- тәкъдимне кире кагу турында, (моңа нигезле сәбәпләрне күрсәтеп).

Ирекләләр эшчәнлеген оештыручы, ирекләләр оешмасы турында өстәмә мәгълүмат соратырга кирәк булган очракта, тәкъдимне карау срогы 10 көнгә озынайтылырга мөмкин.

6. Җирле үзидарә органы, учреждение һәм (яки) оешма ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручыларга, ирекләләр (волонтерлык) оешмаларына кабул ителгән карар турында почта аша исемлекне салып яки Интернет челтәре аша электрон документ формасында (хәбәр җибәрү төренә карап) тәкъдимне карау срогы чыкканнан соң 7 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

7. Тәкъдим кабул ителгән очракта җирле үзидарә органы, учреждение һәм (яки) оешма ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручыларга, ирекләләр (волонтерлык) оешмаларына ирекләләр эшчәнлеген алып бару шартлары турында хәбәр итә;

а) чикләүләр һәм хәвеф-хәтәрләр, шул исәптән ирекләләр эшчәнлеген алып бару белән бәйле зыянлы һәм куркыныч производство факторлары, турында;

б) дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, учреждение һәм (яки) оешманың эш регламентын билгеләүче хокукый нормалар турында;

в) ирекләләр эшчәнлеген башкарганда үтәлергә тиешле таләпләр, куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре һәм башка кагыйдәләр турында;

г) яклар үзара ярдәмләшеп эшләгәндә килеп туган каршылыкларны карау (көйләү) тәртибе һәм сроклары турында;

д) ирекләләр эшчәнлеген алып бару срогы һәм аны срогыннан алда туктату өчен нигез турында;

е) ирекләләр эшчәнлеге алып баруның башка шартлары турында.

8. Ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының тәкъдимнәрен караганнан соң, муниципаль учреждение аны хуплау турында кабул иткән карарга уртак эшчәнлек турында килешү проектын теркәп, яки тәкъдимнән баш тартуын дәлилләп, бер көн эчендә ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының адресына (мөмкин булганда электрон почта аша) хат җибәрә.

9. Учреждение яки оешма ирекләләр эшчәнлеген оештыручының, ирекләләр оешмасының тәкъдимен кире каккан очракта, алар шундый ук тәкъдимне учреждение яки оешманың учредителе булган җирле үзидарә органына җибәрергә хокуклы. Ул гамәлдәге таләпләр куйган тәртиптә карала.

10. Җирле үзидарә органнары, учреждениеләр һәм (яки) оешмаларның ирекләләр эшчәнлеген оештыручы, ирекләләр оешмасы белән үзара

ярдәмләшүе, яклар билгеләгән очраклардан тыш, ярдәмләшү турында килешү (алга таба- килешү) нигезендә корыла.

11. Учреждение һәм (яки) оешма белән килешү төзү срогы иреклеләр эшчәнлеген оештыручы, ирекләләр оешмасы тәкъдимне хуплау турындагы карарны алган көннән башлап,14 эш көненнән дә артмаска тиеш.

12. Килешү төзү, килешү проектын хәл итү процессында туган каршылыкларны көйләү процедурасы җирле үзидарә тарафыннан ирекләләр эшчәнлеген оештыручы, ирекләләр оешмасы белән үзара ярдәмләшү максатыннан расланган үзара ярдәмләшү тәртибе белән билгеләнә.

13. Муниципаль учреждение белән ирекләләр (волонтерлар) оешмасы арасында бергә эшләү турында килешү төзегәндә, учреждение ирекләләр (волонтерлар) оешмасының һәм ирекләләр (волонтерлар) эшчәнлеген оештыручының вәкилләре белән үзара булышып эшләү өчен җаваплы хезмәткәрне билгеләргә тиеш.

14. Җирле үзидарә органы, учреждение һәм (яки) оешма тарафыннан тәкъдимне хуплау турында карар кабул ителгән очракта, ирекләләр эшчәнлеген оештыручы, ирекләләр оешмасы белән килешү төзелә һәм ул түбәндәгеләрне күздә тота:

а) ирекләләр эшчәнлеген оештыручы һәм ирекләләр оешмасы тарафыннан 1995 елның 11 августындагы 135 санлы «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекле лек (волонтерлык) турында»гы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктында күрсәтелгән максатларда алып барыла торган эшләр (хезмәт) төре исемлеге;

б) ирекле эшчәнлек алып бару шартлары;

в) килеп туган мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен, ирекләләр эшчәнлеген оештыручы, ирекләләр оешмасы ягыннан һәм дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, учреждение һәм оешмалар ягыннан, үзара ярдәмләшеп эшләү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләр турында мәгълүматлар;

г) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, учреждение һәм оешмаларның ирекләләр эшчәнлеген оештыручыга, ирекләләр оешмасына ирекләләрне җәлеп итү кирәклеге турында хәбәр итү тәртибе;

д) дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, учреждение һәм (яки) оешма тарафыннан Федераль закон белән каралган ярдәм чаралары күрсәтү, биналар һәм җиһаз бирү мөмкинлеге;

е) ирекләлекне (волонтерлыкны) үстерү сферасы бердәм мәгълүмат системасында ирекләләрнең эшчәнлеген исәпкә алу мөмкинлеге;

ж) ирекләләр эшчәнлеген оештыручының, ирекләләр оешмасының ирекләләрне, федераль орган вәкаләт биргән башкарма хакимият тарафыннан куелган таләпләрне күздә тотып, эшчәнлекләре белән бәйле хәвеф-хәтәрләр (булган очракта) турында таныштыру бурычы;

з) ирекләләр эшчәнлеген оештыручының, ирекләләр оешмасының ирекләләрне ирекләләр эшчәнлеге

алып баруга комачау итүче кичерелгән һәм ачыкланган йогышлы авырулары турында белдерергә тиешле икәнлекләре турында хәбәр итәргә, шулай ук әлеге мәгълүматны эштә исәпкә алырга бурычлы булуы;

и) Россия Федерациясе законнарына каршы килмәүче башка кагыйдәләр.

15. Җирле үзидарә органнары 1995 елның 11 августындагы 135 санлы «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекле (волонтерлык) турында»гы Федераль законда, Татарстан Республикасының 2018 елның 21 июнендәге 48 санлы «Ирекле (волонтерлык) өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне көйләү турында һәм Татарстан Республикасының кайбер законнар актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Карарында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка хокукый-норматив актларында каралган формаларда ирекле (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итәләр.